| Республика Татарстан<br>Менделеевский<br>муниципальный район<br>Глава города<br>Менделеевск | Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль<br>районы<br>Менделеевск шәһәре<br>башлыгы |
|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| ____05.10.2023__________ | Менделеевск ш. | № 62__ |

Гавами тыңлаулар уздыру турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәрендә яшәүчеләрнең хокукларын үтәү максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясе территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2018 елның 7 августындагы 60 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып,

КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. 2023 елның 13 октябренә кадәр әлеге карарны «Менделеевск яңалыклары» газетасында бастырып чыгарырга

3. Гавами тыңлаулар урыны итеп ТР, Менделеевск районы, Менделеевск шәһәре, Яшел урам, 23 йорт адресы буенча урнашкан Балалар сәнгать мәктәбе бинасын билгеләргә. Үткәрү вакыты 2023 елның 27 октябре 17 сәгать 30 минут

4. Фикер алышу турында мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм киңәшләр, гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адреска тәкъдим ителергә мөмкин: Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 7 йорт, 1 кат, район Советының оештыру бүлеге (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр)

5. Гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү срогы 2023 елның 27 октябренә кадәр

6. Район Советының оештыру бүлегенә «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Менделеевск шәһәр

Советының карары проекты буенча билгеләнгән тәртип һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Менделеевск шәһәре башлыгы Р.И.Беляев